ГЛАВА НОВОИМЯНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯҢА ИМӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**20 март 2024 ел** **№1**

2023 елның 22 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Күтәмәле авылы гражданнары халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге
Күтәмәле авылы гражданнарының халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. "2023 елның 22 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Күтәмәле авылы гражданнарының халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Күтәмәле авылы гражданнары халык җыенын Күтәмәле авылы мәдәният йорты бинасында, Күтәмәле авылы Гагарин урамы 39 йорт адресы буенча, 2024 елның 30 мартына 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елның 22 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Күтәмәле авылы гражданнарының халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылында

гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

«1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Күтәмәле авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Күтэмэле торак пункты чикләрендә юлларны кардан чистарту (тракторчы хезмәтләре өчен түләү);
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Күтәмәле авылында триммерлар һәм генератор өчен запчасть һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу; МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары, өстәмә асылмалы, тагылма җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү); халык күпләп ял итә торган урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (сабантуй мәйданына төзү материаллар, сэхнэ сатып алу , скамейкалар сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү );
4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (Күтәмәле авылында янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүченең хезмәте өчен түләү)
5. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Күтәмәле авылында - "Шамгун", "Миннәхмәт" чишмәләрен тозекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;
6. Яр буйларын, сулыкларны чистарту (Күтәмәле авылы сулыкларында агачларны кисү,шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
7. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Күтәмәле авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның һәйкәлен ремонтлау)?";

"ӘЙЕ" "ЮК"?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Яңа Имән авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Күтәмәле авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф.Гәрәев